2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авылы җирлеге Сабанче авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

30 ноябрь 2024 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Сабанче авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Сабанче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту яктырткычларын сатып алу һәм алыштыру); торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны асфальтлау, вак таш сатып алу.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Сабанче авылы, Җаббаров урамы, 1 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кәләй авыл җирлеге башлыгы С.П. Бастылева